**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен
татар теленнән республика олимпиадасының
муниципаль туры сораулары җаваплары
2017-2018 уку елы. 9 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты 180 минут**
**максималь балл - 78**

**I. Тестлардан берәр дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Җөмләдәге тартыклар чиратлашуы күзәтелгән сүзләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.(2 балл)

*Хәсән Туфан кешенең бөеклегенә, аның иксез-чиксез акылына, күңел байлыгына сокланды, шуларны ачып бирергә тырышты.* (Г.Бәширов)

а) бөеклегенә;
ә) байлыгына;
**б) бөеклегенә, байлыгына;**
в) бөеклегенә, байлыгына, сокланды, тырышты.

2. Ф.Садриев иҗатыннан тупланган мисаллар арасыннан протеза күренеше чагылыш тапкан сүз булган җөмләне билгеләгез. (2 балл)

а) Төш алдыннан әни безне ашарга чакырды.
**ә) Тиз-тиз кулларымны юдым да өстәл артына уздым.**
б) Борынга тәмле бәрәңге исе килеп бәрелде.
в) Берсен авызга алып кабуга, ул шикәр кебек таралып та китте.

3. Р.Мингалим иҗатыннан тупланган мисаллар арасыннан архаизм кулланылган җөмләне билгеләгез. (2 балл)

а) Кабан күле турында халыкта шундый риваять тә бар.
ә) Әгәр дә бу шәһәрне күрергә теләсәң, эңгер иңгән сәгатьтә көймәдә күлнең уртасына йөзеп чыгарга кирәк.
б) Һава тып-тын булса, су астындагы манарадан әйтелгән азанны да ишетә аласың, имеш.
**в) Ташларның берсендә, монда Мир Мәхмүт углы Хәсәнбәк күмелгән, диелә.**

4. Гарәп алынмасы кулланылган рәтне билгеләгез. (2 балл)

а) дүшәмбе;
ә) якшәмбе;
**б) җомга;**
в) шимбә.

5. Җөмләдәге ясалма сүзләр саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

*Фән биеклекләренә менәргә хыялланган егет-кызлар иң беренче вуз баскычларын шушында атлап менәләр.* (Ф.Яруллин)

а) 3;ә) 4;**б) 5;**в) 6.

6. Н.Дәүли иҗатыннан тупланган мисаллар арасыннан артыклык дәрәҗәсендәге сыйфат кулланылган җөмләне билгеләгез. (2 балл)

а) Вакыт бик тиз уза шул.

ә) Сары яфраклар шыбырдап җиргә коелдылар.

б) Шул көнәрдә кошлар да ерак-ерак җиргә китеп бардылар.

**в) Аңа бик салкын булыр инде.**

7. С.Җәләл иҗатыннан тупланган мисаллар арасыннан 2 төр хәл фигыль кулланылган җөмләне билгеләгез. (2 балл)

а) Иге-чиге булмаган күктәге кояш иртәдән кичкә кадәр җир йөзенә үзенең нурларын чәчә.

ә) Бакчадагы гөлләр аның җылы нурлары астында көннән-көн матурлана баралар.

**б) Елгаларны томалаган калын бозлар, шаулаша-шаулаша, каядыр еракка китеп беттеләр.**

в) Елга суы гына, үзенең ярын тутырып, тиз-тиз алга йөгерә.

8. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән алмашлыкның төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

*Көзге вак яңгыр тыныч кына сибәли дә тирә-якны* ***ниндидер*** *бер моңга, ят хискә чылатып китә.* (А.Мансуров)

а) юклык;

**ә) билгесезлек;**

б) билгеләү;

в) сорау.

9. Мәкальдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең кайсы сүз төркеменә караганлыгы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

***Батыр*** *ут булыр,* ***куркак*** *юк булыр.*

а) исемнәр;

ә) сыйфатлар;

б) сыйфат фигыльләр;

**в) исемләшкән сыйфатлар.**

10. Ә.Еники иҗатыннан тупланган мисаллардан эндәш сүз кулланылган җөмләне билгеләгез. (2 балл)

а) Син икәнсең инде ул Клара, ә?

ә) Сез... Рәхмәй абый буласызмы?

б) Әйдүк, хуш киләсең!

**в) Бик якын туганнар бит без, уйласаң, Клара аккошым.**

11. Иярчен җөмләнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

*Һәр фил озын борынлы булса да, һәр озынборын фил булмый.* (Мәкаль)

а) аналитик иярчен кире җөмлә;

**ә) синтетик иярчен кире җөмлә;**

б) аналитик иярчен шарт җөмлә;

в) синтетик иярчен шарт җөмлә.

12. Кушма җөмләнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

*Көзге җилләр саргайган агач яфракларын коеп, дачаның яме китә башлагач, ял итеп ятучылар шәһәргә күчте.* (Г.Бакиров)

а) тиңдәш иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;

ә) тиңдәш түгел иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;

**б) бер-бер артлы иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;**

в) берничә төр иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә.

## II. Башыгызны эшләтегез.

Елга исемнәренең татарча атамаларын языгыз. (10 балл)

Волга – (Идел)

Кама – (Чулман)

Вятка – (Нократ)

Зай – (Зәй)

Белая – (Агыйдел)

Свияга – (Зөя)

Ик – (Ык)

Казанка – (Казансу)

Мёша – (Мишә)

Шошма – (Шушма)

## III.Теоретик бирем.

Хәл фигыльләр турында белгәннәрегезне языгыз. Ни өчен ул хәл фигыль дип атала? Фикерегезне мисаллар ярдәмендә дәлилләгез. Хәл фигыльләрнең дөрес язылышына караган кагыйләрне күрсәтегез. (10 балл)

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

*Алдыңда зур максат булса, йөрәгең эштә дә ял итә.* (Мәкаль)

1. *Йөрәгең* сүзенә фонетик анализ ясагыз. (5 балл)
2. *Алдыңда* сүзенең мәгънәле кисәкләрен билгеләгез. (3 балл)
3. *Зур, булса, йөрәгең, дә* сүзләренә морфологик анализ ясагыз. (8 балл)
4. Җөмләнең баш кисәкләрен һәм компонент чикләрен билгеләгез, схемасын сызыгыз, җөмләгә билгеләмә бирегез. (8 балл)
5. Әлеге тема белән бәйле фикерләрегезне 12-15 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. (10 балл)

Текст язуга таләпләр:

- текст төзелеше ( башлам, төп өлеш, йомгаклау);
- җөмләләр дөрес, төзек булырга тиеш;
- язма телнең  бай, сурәтле булуына  игътибар итәргә;
- орфографик грамоталылыкка игътибарлы булырга.